**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Кадыровского**
**сельского поселения Заинского**
**муниципального района**

ул. Молодежная , д. 1. с. Кадырово,
Заинский район, 423513

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

Яшьләр урамы, 1 нче йорт. Кадер авылы,
Зәй районы, 423513

Телефон, факс 63-3-18. Электронный адрес: Kadir.zai@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**10 декабрь 2019 ел** **№ 19**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 нчы елның 29 маендагы 8 нче номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләренә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 16.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законы, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге администрациясе тарафыннан расланган нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.1 пунктына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 29 маендагы 8 нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлеге администрациясе тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе

турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) күчемсез милек белән идарә итүгә ышанычнамәләреннән тыш, ышаныч кәгазен раслау;»;

1.3. 3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) мирас мөлкәте исемлеген җитештерү юлы белән мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрергә;».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы Кадер авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.М. Нуруллин**